КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 7 март г.Казань № 180

Апас муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Җирләрне яки җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Апас муниципаль районында урнашкан 6,8688 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен кушымта нигезендә ял (рекреация) объектларын урнаштыру максатларында махсус саклана торган территорияләр һәм объектлар җирләре категориясенә күчерергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 ел, 7 март, 180 нче карарына кушымта

Махсус саклана торган территорияләр һәм объектлар категорияләренә күчерелә торган җир кишәрлекләре исемлеге

| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Мәйданы, гектар | Муниципаль район исеме |
|---|---|---|
| 16:08:080405:249 | 4,5111 | Апас |
| 16:08:190405:282 | 2,3577 | |
| Барлыгы | 6,8688 | |

-----------------